ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24 октябрь 2025 ел** **№ 3**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында, Подстанция Киндери урамы 1 нче номерлы йорт янындагы адрес буенча 2025 елның 8 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2026 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- урам яктырту эшләрен башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районың Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов